ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 февралендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 8 (II өлеш), № 12 (X өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 12 (I өлеш); 2012, № 1, № 9; 2014, № 6 (II өлеш), № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендә «шушы гражданнарның яшәү урыны буенча бирелгән гаризалары нигезендә вәкаләтле орган» сүзләрен «вәкаләтле орган шушы гражданнарның күрсәтелгән органга алар тарафыннан яшәү урыны буенча бирелгән яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәге аша юлланган гаризалары нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

2) 5 статьяда:

а) икенче абзацта «социаль наем шартнамәләре» сүзләреннән соң «, социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре» сүзләрен өстәргә, «социаль наем шартнамәсе» сүзләреннән соң «, социаль файдаланудагы торак фондының торак урынына наем шартнамәсе» сүзләрен өстәргә;

б) өченче абзацта «социаль наем шартнамәләре» сүзләреннән соң «, социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре» сүзләрен өстәргә, «социаль наем шартнамәсе» сүзләреннән соң «, социаль файдаланудагы торак фондының торак урынына наем шартнамәсе» сүзләрен өстәргә;

в) бишенче абзацта «социаль наем шартнамәләре» сүзләреннән соң «, социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре» сүзләрен

өстәргә, ике урында «социаль наем шартнамәсе» сүзләреннән соң «, социаль файдаланудагы торак фондының торак урынына наем шартнамәсе» сүзләрен өстәргә;

3) 15 статьяның 2 өлешендәге дүртенче абзацында «гараж-төзелеш һәм дача-төзелеш» сүзләрен «гараж һәм дача кулланучылар» сүзләренә алмаштырырга;

4) 18 статьяда:

а) 1 өлештә «тиешле күчемсез мөлкәт объектларын техник исәпкә алуны һәм инвентарьлаштыруны үткәрүгә аккредитацияләнгән оешмалардан» сүзләрен «күчемсез мөлкәтне кадастр исәбенә алуны һәм аның дәүләт кадастрын алып баруны гамәлгә ашыра торган органнан тиешле» сүзләренә алмаштырырга, «инвентарьлаштырылган» сүзен «кадастр» сүзенә алмаштырырга, «инвентарьлаштыру» сүзен «кадастр» сүзенә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «, ә аны билгеләгәнчегә кадәр, җир турындагы законнарга таянып, җирнең норматив бәясе нигезендә билгеләнә» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 20 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Торак-төзелеш, гараж һәм дача кулланучылар кооперативларында пай җыелмалары хакын билгеләү мөрәҗәгать итүче граждан тарафыннан бирелгән һәм торак-төзелеш, гараж һәм дача кулланучылар кооперативлары тарафыннан танылканган белешмәләр нигезендә башкарыла.»;

6) 25 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

«4. Торак урыннарына мохтаҗлар буларак вәкаләтле орган тарафыннан яшәү урыны буенча исәпкә куелган һәм социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча башка муниципаль берәмлек чикләрендә урнашкан торак урыннары бирелүгә бәйле рәвештә яшәү урынын үзгәрткән гражданнар торак урыннарына мохтаҗлар буларак аларның элекке яшәү урыны буенча исәптән төшерелергә тиеш түгел.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2015 елның 16 марты
№ 15-ТРЗ

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН